**ГЛАВА**
**Кичкетанского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кичкетаң авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

05.10.2022 Кичкетан авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 18 октябрендә 14 сәг. 00 мин. гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2023 елда үзара салым акчаларын кертүгә һәм куллануга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кичкетаң авыл җирлеге” торак пункты территориясендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт узучы затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллап, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану”:

1. Су белән тәэмин итү (насослар сатып алу, суүткәргеч линияләрен ремонтлау).

2. Урам яктырткычларын сатып алу.

3. Кичкетаң авылы урамнарын кардан чистарту (ГСМ сатып алу).

4. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү.(ГСМ, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу).

5. Санланмаган чүплекләрне бетерү.

6. Кичкетаң авылының Татарстан урамындагы күперне ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кичкетаң ав., М.Җәлил ур., 2 йорт адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы З.Р. Нуриев

Совет Кичкетанского сельского поселения Кичкетаң авыл җирлеге Советы ИНН 1601002452 · АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ